Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Шәмбалыкчы авыл җирлеге Башкарма комитеты

Карар

2025 ел, 17 июль №14

«Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Шәмбалыкчы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампаларны туплау урыны (урыны) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 14 мартындагы 300 номерлы "Дәүләт экология мониторингы (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингы) турында нигезләмәне раслау хакында" карары нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Шәмбалыкчы авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Шәмбалыкчы авыл җирлеге Башкарма комитетының « «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Шәмбалыкчы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампаларны туплау урыны (урыны) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү турында» 2023 елның 7 апрелендәге 4 номерлы түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

“4. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Шәмбалыкчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге эшкәртелгән терекөмешле лампалар туплау урыннарының урнашуы турында мәгълүматны кулланучыларга әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мондый урыннарның урнашуы турында мәгълүмат урнаштыру юлы белән бирергә.”.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Шәмбалыкчы
авыл җирлеге Башлыгы Ф.Ф.Миннуллин